

*Мин кечкенә Сөмбелә,*
*“Тамчыкай” бакчасыннан.*
*Исемем минем Айсылу,*
*Дусларым да күп кенә.*



***Кояш нуры иркәләп,***
***Уята мине иртән.***
***Әй, йөгерәм бакчага,***
***Анда дусларым көтә!***



*Укыйбыз да, язабыз да*
*Рәсемнәр дә ясыйбыз.*
*Спорт белән шөгыльләнеп*
*Көч- куәт тә җыябыз!*



*Бәйгедә катнашырга дип,*
*Килдем әле мин бүген!*
*Матур күлмәгемне кидем,*
*Шатландырып күк йөзен!*



***Сөмбелә ул шундый бәйрәм,***
***Көзне - җәйдән белдерә.***
***Иген - ашлык уңса гына,***
***Шатландыра, көлдерә!***



***Барчабызга уңыш телим,***
***Аяз булсын күк йөзе!***
***Аш-сулардан сыгылып торсын,***
***Барчабызның өстәле!***